КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

19.09.2024 №189-п

«Татарстан Республикасы бюджетына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы администратор булган түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2023 елның 18 декабрендәге 229-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы администратор булган түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татарстан Республикасы бюджетына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы администратор булган түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2023 елның 18 декабрендәге 229-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы администратор булган түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны каплау йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән гражданны – индивидуаль эшкуарны өлешендә банкрот дип тану процедурасы тәмамлану.

Күрсәтелгән факт түбәндәге документлар белән раслана:

конкурс эше тәгәлләнү яисә гражданның – индивидуаль эшкуар булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр кертүченең мөлкәтен сату тәмамлану турындагы суд акты, шулай ук физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр кертүченең бөлгенлеккә төшүен (банкрот) тану турында суд акты чыгарылуга бәйле рәвештә аның индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктатуы турында Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмә булган документ;

конкурс эше тәгәлләнү яисә гражданның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр кертүченең мөлкәтен сату тәмамлану турындагы суд акты;»;

«в» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) штраф салу рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында йә аларны ярлыкау хакында актлар куллану яисә Агентлыкның Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеге юкка чыгуы турында суд карары чыгу, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы узуга бәйле рәвештә, ул штраф салу рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия хакында яки аларны ярлыкау турында акт яисә Агентлыкның Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеге юкка чыгуы хакында суд акты белән раслана;»;

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) бурычның күләме банкротлык турында эш кузгату өчен Россия Федерациясенең бөлгенлек (банкротлык) турындагы законнарында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләр күләменнән артык булмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык вакыт узган булса, һәм «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында (алга таба – 229-ФЗ номерлы Федераль закон) каралган нигезләр буенча башкару документын бурычны түләттерүчегә кире кайтарган очракта суд приставы – башкаручысының башкару эше тәмамлану турында карар чыгаруы.

Күрсәтелгән фактны раслаучы документлар булып суд приставы – башкаручысының 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигездә башкару документын түләттерүчегә кире кайтаруга бәйле башкару эше тәгәлләнү хакындагы карары тора;»;

түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәргә:

«з) судның бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтару хакында яисә банкротлык эшендә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле банкротлык турында эшне туктату хакында акт чыгаруы, бу – бурычлыны бөлген (банкрот) дип тану турындагы гаризаны кире кайтару турында суд яисә банкротлык эшендә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча

булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты белән раслана.»;

6 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турындагы мәсьәләне документлар кергән көннән алып 5 эш көне эчендә әлеге документлар нигезендә карый. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турындагы мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы узган көннән алып 10 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану турында карар әзерләнә.

Әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тану өчен нигезләр булмау турында мәгълүмат бирелә.».

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф. Миргалимов